КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 гыйнвар г.Казань № 10

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы; 2021 ел, 15 сентябрь, 877 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1355 нче, 2023 ел, 20 февраль, 162 нче, 2023 ел, 21 март, 308 нче, 2023 ел, 3 июнь, 684 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында нигезләмәгә, 7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«муниципаль дәрәҗәдә - җирле үзидарә органнары каршында төзелә торган халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле органнар;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе турында» 2011 ел, 29 июнь, 530 нчы

карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 25 февраль, 163 нче, 2014 ел, 16 май, 323 нче, 2014 ел, 22 август, 606 нчы, 2016 ел, 25 октябрь, 777 нче, 2021 ел, 08 июнь, 437 нче, 2023 ел, 21 март, 308 нче, 2023 ел, 11 июль, 810 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны уртаклашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат критерийларын раслау хакында» 2004 елның 08 июлендәге 329 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы)» сүзләрен «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат критерийларын билгеләү турында» 2021 елның 5 июлендәге 429 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта искәрмәсенә «стихияле бәла-казалар» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы буенча» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин